ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29 апрель 2022ел № 2262

Башкарма комитетның 2021 елның 7 июнендәге 3888 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә электр самокатларын прокатка бирү пунктларыннан файдалану тәртибенә үзгәрешләр кертү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Шәһәр Советының 2007 елның 22 февралендәге 19/8 номерлы карары белән расланган Муниципаль хокукый актлар системасы турында нигезләмәнең 5.24 пункты нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның 2021 елның 7 июнендәге 3888 номерлы карары (Башкарма комитетның 2021 елның 19 августындагы 5527 номерлы карары редакциясендә) белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә электр самокатларын прокатка бирү пунктларыннан файдалану тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 пунктка түбәндәге эчтәлектәге абзац өстәргә:

«Электр самокатларын прокатка бирү пунктларын урнаштыру Башкарма комитетның 2021 елның 4404 номерлы карары белән расланган җир участоклары бирмичә һәм сервитут, җәмәгать сервитуты билгеләмичә, дәүләт яки муниципаль милектәге җирләрдән яки җир участогыннан файдалануга рөхсәт бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

2) 6 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6. Электр самокатларын, электр самокатларын прокатка бирү пунктыннан читтә, электр самокатларын прокатка бирү пункты хуҗасына (иясенә) калдыру һәм кире кайтару тыела. Электр самокатларын прокатка бирү пунктыннан читтә калдырылган электр самокаты әлеге тәртипнең 3 бүлеге нигезендә күчерелергә тиеш.»;

3) 9 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«9. Электр самокатларын прокатка бирү пунктын ачыклау, демонтажлау (күчерү), мәйданы чикләре билгеләрен бетерү әлеге тәртипнең 4 бүлеге нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

3) түбәндәге эчтәлектәге 3 һәм 4 бүлекләр өстәргә:

«3. Электр самокатларын прокатка бирү пунктларыннан читтә урнашкан электр самокатларын күчерү һәм кире кайтару тәртибе

11. Башкарма комитетның район хакимиятенең вазыйфаи заты тарафыннан электр самокатларын прокатка бирү пунктыннан читтә урнашкан электр самокаты ачыклаганда, Башкарма комитетның район хакимиятенең вазыйфаи заты, әлеге тәртипкә 1 нче кушымтада каралган форма буенча, электр самокатларын прокатка бирү пунктыннан читтә урнашкан электр самокатын ачыклау турында акт (алга таба – акт) төзи.

12. Электр самокаты идентификация номерына ия булса яисә аның электр самокаты хуҗасына (иясенә) каравын билгеләргә мөмкинлек бирә торган номеры булса, Башкарма комитетның район хакимиятенең вазыйфаи заты, телефон элемтәсе аша яисә электр самокатларын прокатка бирү хезмәте күрсәтүче оператор кушымтасы аша башка мөмкин булган ысул белән, электр самокаты хуҗасын (иясен) эзләүне гамәлгә ашыра, аның хуҗасына (иясенә) электр самокатының урнашу урынын хәбәр итә һәм актта тиешле билге ясый.

Электр самокаты хуҗасы (иясе), телефон элемтәсе аша яисә электр самокатларын прокатка бирү хезмәте күрсәтүче оператор кушымтасы аша башка мөмкин булган ысул белән хәбәр ителгәннән соң, бер сәгать эчендә электр самокаты урнашкан урынга килгән очракта, Башкарма комитетның район хакимиятенең вазыйфаи заты әлеге электр самокатының кемгә каравын тикшерә, актта тиешле билге ясый, Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының (алга таба – Административ хокук бозулар турында ТР кодексы) 2.6 статьясы буенча административ хокук бозу турында беркетмә төзи, электр самокатын электр самокаты хуҗасына (иясенә) кайтара һәм актта тиешле билге ясый.

Электр самокаты хуҗасы (иясе) хәбәр иткәннән соң электр самокаты урнашкан урынына килмәгән очракта, вазыйфаи зат ачыкланган электр самокатының хуҗасын (иясен) билгеләү һәм алга таба аны законда билгеләнгән тәртиптә Административ хокук бозулар турында ТР кодексының 2.6 статьясы буенча административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә.

13. Электр самокаты хуҗасын (иясен) билгеләү мөмкинлеге булмаганда яисә мөмкин булган ысуллар белән хәбәр иткәннән соң, электр самокаты хуҗасы (иясе) күрсәтелгән вакытта һәм урынга килмәсә, Башкарма комитетның район хакимиятенең вазыйфаи заты, электр самокатының хуҗасы (иясе) килмәү турындагы мәгълүматларны кертеп, әлеге тәртипнең 1 нче кушымтасында каралган форма буенча акт төзи, әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган электр самокатын саклау мәйданчыгына күчерү буенча кичектергесез гамәлләрне башкара.

14. Прокат пунктыннан читтә ачыкланган электр самокатлары турында мәгълүмат, Башкарма комитетның район хакимиятенең вазыйфаи затлары тарафыннан «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырыла.

15. Әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган, саклана торган электр самокатын кире кайтару өчен электр самокатының хуҗасы (иясе) гариза белән Башкарма комитетның район хакимиятенә мөрәҗәгать итә. Гаризага электр самокатының кемгә каравын раслаучы документларны терки.

16. Башкарма комитетның район хакимиятенең вазыйфаи заты гариза бирүченең шәхесен билгели, электр самокатының кемгә каравын тикшерә, электр самокатын күчерүгә бәйле чыгымнарны түләү өчен квитанция бирә һәм әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган электр самокатының хуҗасын (иясен) административ җаваплылыкка тарту буенча мөмкин булган гамәлләрне башкара.

17. Электр самокатының хуҗасы (иясе) электр самокатының кемгә каравын, электр самокатын күчерүгә бәйле чыгымнарны түләүне раслаучы документлар белән электр самокатларын саклауны гамәлгә ашыручы оешмага мөрәҗәгать итә һәм электр самокатын кире кайтаруны гамәлгә ашыра.

## 4. Билгеләнгән тәртипне бозып урнаштырылган электр самокатларын прокатка бирү пунктларын ачыклау тәртибе

18. Әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып, муниципаль милектә яки дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә урнаштырылган электр самокатларын прокатка бирү пункты объекты, электр самокатын прокатка бирү пункты мәйданчыгы (алга таба – прокат пункты, мәйданчык) ачыкланганда, район хакимиятенең вазыйфаи затлары әлеге тәртипкә 2 нче кушымтада каралган форма буенча акт төзи.

19. Әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган прокат пункты ачыклаганда прокат пунктының хуҗасы (иясе) билгеләнгән очракта, Башкарма комитетның район хакимиятенең вазыйфаи заты прокат пункты хуҗасына (иясенә) карата Административ хокук бозулар турында ТР кодексының 2.6 статьясы буенча административ хокук бозу турында беркетмә төзи, шулай ук, имза куйдырып, прокат пункты хуҗасына (иясенә) (вәкаләтле вәкилгә), әлеге тәртипкә 3 нче кушымта нигезендә, прокат пунктын ирекле рәвештә демонтажлау (күчерү), чикләре билгеләрен бетерү турында күрсәтмә тапшыра.

20. Прокат пункты хуҗасы (иясе) билгеләнмәгән очракта, район хакимиятенең вазыйфаи затлары прокат пунктының хуҗасын (иясен) билгеләү һәм алга таба аны Административ хокук бозулар турында ТР кодексының 2.6 статьясы буенча административ җаваплылыкка тарту буенча чаралар күрә, шулай ук күрсәтмәнең күчермәсен турыдан-туры прокат пунктында яисә мәйданчыкта урнаштыра, бу хакта күрсәтмә бланкында тиешле билге ясала һәм бер эш көне эчендә күрсәтмәнең күчермәсен «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыра.

21. Әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган прокат пунктлары турында мәгълүмат Башкарма комитетның район хакимиятләренең вазыйфаи затлары тарафыннан «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырыла.

22. Әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган прокат пункты хуҗасы (иясе) кулына тапшырылган, «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштырган вакыттан башлап бер тәүлек эчендә, үз көче белән һәм үз хисабына, законсыз рәвештә прокат пункты урнаштырылган

урынны бушатырга һәм законсыз рәвештә прокат пункты урнаштырылган урынны элекке хәленә китерергә тиеш.

23. Нигезләмәнең 22 пунктында билгеләнгән срок эчендә, мондый прокат пунктының хуҗасы (иясе) тарафыннан прокат пункты демонтажланмаса, күчерелмәсә, мәйданчык чикләре билгеләре ирекле тәртиптә бетерелмәсә, район хакимиятенең вазыйфаи затлары бер эш көне эчендә әлеге тәртипкә 4 нче кушымтада каралган форма буенча, әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган прокат пунктын демонтажлау, күчерү, мәйданчык чикләре билгеләрен бетерү турында Башкарма комитет карары проектын әзерләүне гамәлгә ашыралар һәм аны билгеләнгән тәртиптә килештерәләр.

24. Әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган прокат пунктын демонтажлау, күчерү, мәйданчык чикләре билгеләрен бетерү турында Башкарма комитет карары имзаланган һәм теркәлгән көнне район хакимиятенең вазыйфаи затлары прокат пунктын махсуслаштырылган саклау мәйданчыгына демонтажлау (күчерү) яисә прокат пункты мәйданчыгының чикләре билгеләрен бетерү буенча чаралар күрә.

25. Прокат пунктын демонтажлаганда (күчергәндә), анда булган мөлкәт әлеге тәртипкә 5 нче кушымтада каралган форма буенча, район хакимиятенең вазыйфаи затлары тарафыннан төзелә торган исемлеккә кертелергә тиеш.

Прокат пункты мәйданчыгының чикләре билгеләрен бетергәндә, мәйданчыкта урнашкан электр самокатлары, әлеге тәртипкә 5 нче кушымтада каралган форма буенча, район хакимиятенең вазыйфаи затлары тарафыннан төзелә торган исемлеккә кертелергә тиеш.

26. Прокат пунктын демонтажлау (күчерү), төяү-бушату, аның чикләре билгеләрен бетерү эшләре тиешенчә башкарылмау нәтиҗәсендә югалту, җитмәү яки прокат пункты хуҗасына (иясенә) китерелгән зыян өчен, законда билгеләнгән тәртиптә Башкарма комитет тарафыннан билгеләнгән махсус оешма җавап бирә.

27. Прокат пункты хуҗасы (иясе), саклаудагы прокат пункты объектын (аның составындагы элементларны) һәм демонтажланган прокат пункты объектында булган яисә прокат пункты мәйданчыгындагы мөлкәтне кире кайтару максатында, гариза белән Башкарма комитетның тиешле район хакимиятенә мөрәҗәгать итә.

Гаризага прокат пункты объектының кемгә каравын раслаучы документларны терки.

Башкарма комитетның район хакимиятенең вазыйфаи заты гариза бирүченең шәхесен билгели, прокат пункты объектының кемгә каравын тикшерә, прокат пунктын демонтажлауга (күчерүгә), аның чикләре билгеләрен бетерүгә бәйле чыгымнарны түләү өчен квитанция бирә һәм әлеге карарда билгеләнгән таләпләрне бозып урнаштырылган прокат пункты хуҗасын (иясен) административ җаваплылыкка тарту буенча мөмкин булган гамәлләрне башкара.

28. Прокат пункты объектын һәм аның эчендә яисә прокат пункты мәйданчыгында булган мөлкәтне кире кайтару, әлеге тәртипкә 7 нче кушымтада каралган форма буенча, прокат пункты объектын һәм прокат пункты объектында яки прокат пункты мәйданчыгында булган мөлкәтне кабул итү-тапшыру акты нигезендә, югарыда күрсәтелгән объектларны саклауны гамәлгә ашыручы махсуслаштырылган оешма тарафыннан башкарыла.

29. Прокат пункты объектын, прокат пункты объектында яисә прокат пункты мәйданчыгында булган мөлкәтне махсуслаштырылган саклау мәйданчыгына

күчергән көннән башлап 30 календарь көн эчендә, Башкарма комитетның тиешле район хакимиятенең вазыйфаи затлары прокат пункты объекты, прокат пункты объектында яисә прокат пункты мәйданчыгында булган мөлкәт хуҗасына (иясенә) 6 нчы кушымтада каралган форма буенча белдерү кәгазе җибәрәләр һәм мондый белдерү кәгазен «Интернет» челтәрендә Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыралар.

30. Электр самокатларын прокатка бирү пункты объектларын, прокат пунктында яисә электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгында булган мөлкәтне саклау алты ай дәвамында гамәлгә ашырыла.

31. Электр самокатларын прокатка бирү пункты объектын, шулай ук анда яисә электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгында булган мөлкәтне махсуслаштырылган саклау мәйданчыгына күчергән көннән башлап алты ай узганнан соң, Башкарма комитет тарафыннан күрсәтелгән мөлкәтне хуҗасыз дип тану һәм аңа карата муниципаль милек хокукын тану буенча чаралар күрелә.»;

4) 1-7 нче кушымталарда каралганча 1-7 кушымталар өстәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны рәсми бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитетның Автозавод районы хакимияте Башлыгы В.Х. Харисовка, Башкарма комитетның Үзәк районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы А.С. Тарабукинга, Башкарма комитетның Комсомол районы хакимияте Башлыгы вазыйфаларын башкаручы Ф.Ф. Хәбибуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2022 елның 29 апрелендәге
2262 номерлы карарына
1 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә электр
самокатларын прокатка бирү
пунктларыннан файдалану тәртибенә
1 нче кушымта

Электр самокатларын прокатка бирү пунктыннан
читтә урнашкан электр самокатын ачыклау турында
АКТ

N ______ "__" _______ 20_ ел

______________________________________________________________________
______________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., район хакимияте вәкилләренең вазыйфасы)

түбәндәге адрес буенча ачыклау турында акт төзеделәр:________________________________________________________
______________________________________________________________________
(прокатка бирү пунктыннан читтәге электр самокатының адресы һәм урнашу урыны)
______________________________________________________________________.

Электр самокатының кемгә каравы турында мәгълүмат ______________________________
______________________________________________________________________
(юридик яки физик затның(ШЭ) мәгълүматлары, адресы)

Акт электр самокатының хуҗасы (иясе) (вәкаләтле вәкиле) катнашында төзелде:
_____________________________________________________ ____________
(электр самокаты хуҗасының (иясе)(вәкаләтле вәкиле) Ф.И.А.и. (Имза)
______________________________________________________________________

Район хакимияте вәкилләренең имзасы

______________________________.

Кушымта: электр самокатын урнаштыру фотографиясе.
Электр самокаты хуҗасына (иясенә) карата административ җаваплылыкка тарту турында беркетмә төзелде_________________

Электр самокаты хуҗасына (иясенә) кире кайтарылды.
Претензиям юк _______________ Электр самокаты хуҗасының (иясенең) имзасы.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 29 апрелендәге
2262 номерлы карарына
2 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә электр
самокатларын прокатка бирү
пунктларыннан файдалану тәртибенә
2 нче кушымта

Электр самокатларын прокатка бирү пунктын тикшерү
АКТЫ

N _______ "__" ________ 202_ ел

________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., район хакимияте вәкилләренең вазыйфасы)

әлеге актны түбәндәге адрес буенча:____________________________________________

________________________________________________________________________
(прокатка бирү пунктыннан читтәге электр самокатының адресы һәм урнашу урыны)
________________________________________________________________________.

__________________________________________________урнашу турында төзеделәр.
(объектның тибы)

Нәрсәдән ясалган_______________________________________________________,
төсе ___________________________________________________________________,
үлчәме _________________________________________________________________.

Электр самокатының кемгә каравы турында мәгълүмат ______________________________

________________________________________________________________________
(юридик яки физик затның (ШЭ) мәгълүматлары, адресы)

Акт электр самокатының хуҗасы (иясе) (вәкаләтле вәкиле) катнашында төзелде:
______________________________________________________ _______________
(электр самокаты хуҗасының (иясе)(вәкаләтле вәкиле) Ф.И.А.и. (Имза)
________________________________________________________________________

Район хакимияте вәкилләренең имзасы

______________________________.

Кушымта: объектның фотографиясе.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 29 апрелендәге
2262 номерлы карарына
3 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә электр
самокатларын прокатка бирү
пунктларыннан файдалану тәртибенә
3 нче кушымта

Электр самокатларын прокатка бирү пункты объектын
ирекле рәвештә демонтажлау (күчерү) яисә электр самокатларын прокатка бирү
пункты мәйданчыгының чикләре билгеләрен ирекле рәвештә бетерү турында күрсәтмә

N __________ "__" ____________ 202__ ел

Кемгә: ________________________________________________________________________
(гражданның (ШЭ) Ф.И.А.и. яисә юридик затның исеме һәм адресы)

Тәүлек эчендә ________________________________________________
(күрсәтелә: әлеге күрсәтмәне кулга бирү, почта аша җибәрү һәм "Интернет"челтәрендә шәһәрнең рәсми сайтында урнаштыру вакыты)
__________________________________________________вакыттан башлап

___________________________________________________________________________
___________________________________________________________________________

Сезгә түбәндәге адрес буенча урнашкан:
__________________________________________________

электр самокатларын прокатка бирү пункты объектын ирекле рәвештә, үз көчегез белән һәм үз хисабыгызга саклау урынына демонтажларга (күчерергә)

___________________________________________________________________________,
(күрсәтелә: павильон, киоск һ.б.)

яисә түбәндәге адрес буенча урнашкан:
___________________________________________________________________________
электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгының чикләре билгеләрен ирекле рәвештә бетерергә, шулай ук электр самокатларын прокатка бирү пункты урнашкан урынны, урнашкан мәйданчыкны башлангыч халәтенә китерергә кирәк.

Әлеге күрсәтмә үтәлмәгән очракта электр самокатларын прокатка бирү пункты мәҗбүри рәвештә демонтажланачак (электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгының чикләре билгеләре бетереләчәк).
Күрсәтмә белән таныштым ____________________________________________.
(вазыйфаи затның имзасы, имзаның расшифровкасы)
___________________________________________________________________________

Күрсәтмәдә күрсәтелә:
1) күрсәтмәне алудан һәм аның белән танышуны имзалаудан түбәндәге сәбәп буенча баш тартты:
___________________________________________________________________________
(күрсәтергә) (сәбәпләрен аңлатмыйча);
2) күрсәтмә аны тапшыру турында белдерү кәгазе белән почта аша җибәреләчәк;

3) электр самокатларын прокатка бирү пунктын урнаштыруны, прокатка бирү пункты мәйданчыгын урнаштыруны гамәлгә ашыручы зат ачыкланмаган;

4) күрсәтмә электр самокатларын прокатка бирү пункты объектында, прокатка бирү пункты мәйданчыгында урнаштырылды (фотофиксация белән).

____________________________________________________________

(район хакимияте вәкиленең имзасы, имзаның расшифровкасы)

____________________________________________________________

(вәкаләтле органның адресы, элемтә телефоны)

________________________________________ Башкарма комитетының

________________________________________ районы хакимияте Башлыгы

____________________________________________________________

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы

УПРАВЛЕНИЕ ДЕЛОПРОИЗВОДСТВОМ
ЭШ КӘГАЗЬЛӘРЕН АЛЫП БАРУ ИДАРӘСЕ

Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 29 апрелендәге
2262 номерлы карарына
4 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә электр
самокатларын прокатка бирү
пунктларыннан файдалану тәртибенә
4 нче кушымта

Электр самокатларын прокатка бирү пункты объектын демонтажлау (күчерү), электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгының чикләре билгеләрен бетерү турында

Электр самокатларын прокатка бирү пункты объектын ирекле рәвештә демонтажлау (күчерү) яисә электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгының чикләре билгеләрен ирекле рәвештә бетерү турында күрсәтмәнең үтәлмәве турында актны карап тикшергәннән соң, Башкарма комитетның 2021 елның 7 июнендәге 3888 номерлы карары белән расланган Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә электр самокатларын прокатка бирү пунктларыннан файдалану тәртибе нигезендә

КАРАР БИРӘМ:

1. Башкарма комитетның ________________________________районы хакимиятендә төзелгән __________________ комиссиягә электр самокатларын прокатка бирү пункты объектын демонтажлау (күчерү) яисә электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгының чикләре билгеләрен бетерү буенча эшләрне оештыруны кушымтада каралганча тәэмин итәргә.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Башкарма комитетның

___________________ районы хакимияте Башлыгы Ф.И.А.и.

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 29 апрелендәге
2262 номерлы карарына
5 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә электр
самокатларын прокатка бирү
пунктларыннан файдалану тәртибенә
5 нче кушымта

Электр самокатларын прокатка бирү пункты объектын,
электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгын
демонтажлаганда (күчергәндә) ачыкланган мөлкәт һәм башка материаль байлыкларның
исемлеге

N ________ "__" _________ 202__ ел

________________________________________________________________________________,
(ачыкланган объектның урыны адресы)

адресы буенча урнашкан,
________________________________________________________________ караган
(юридик яки физик затның (ШЭ) мәгълүматлары)

______________________________
(стационар булмаган объектның тибы)
электр самокатларын прокатка бирү пунктын демонтажлаганда (күчергәндә), чикләре билгеләрен бетергәндә түбәндәге материаль байлыклар ачыкланды:

| N т/б | Исеме | Саны |
|---|---|---|
| | | |
| | БАРЛЫГЫ | |

Объектны сүтеп демонтажлаганда (күчергәндә):

| N т/б | Объектның состав материаллары | Үлчәме | Саны |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | БАРЛЫГЫ | | |

Район хакимияте вәкиле: ___________________________________________
(Ф.И.А.и., имза)

Катнашучы затлар: ___________________________________________________________
________________________________________________________________________________
(Ф.И.А.и., вазыйфа, имза)

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 29 апрелендәге
2262 номерлы карарына
6 нчы кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә электр
самокатларын прокатка бирү
пунктларыннан файдалану тәртибенә
6 нчы кушымта

______________________________________________ адресы буенча ачыкланган, билгеләнгән тәртипне бозып урнаштырылган электр самокатларын прокатка бирү пункты объектының, электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгының хуҗасына (иясенә)

Сезгә шул хакта белдерәбез: Сез Башкарма комитетның _______________ районы Хакимиятенә Сезгә караган_______________ объектны, шулай ук андагы ________________________________ адресы буенча саклау мәйданчыгына күчерелгән мөлкәтне кире кайтару турында гариза белән мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Әлеге максат белән Сезгә түбәндәгеләрне тапшырырга кирәк:

- объект һәм мөлкәтнең сезгә каравын раслаучы документлар;

- мөлкәт объектын күчерү һәм саклау белән бәйле чыгымнарны каплауны раслаучы документлар.

Башкарма комитетның

_________________ районы хакимияте Башлыгы

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева

Башкарма комитетның
2022 елның 29 апрелендәге
2262 номерлы карарына
7 нче кушымта

Яр Чаллы шәһәре муниципаль
берәмлеге территориясендә электр
самокатларын прокатка бирү
пунктларыннан файдалану тәртибенә
7 нче кушымта

Электр самокатларын прокатка бирү пункты объектында яки электр самокатларын прокатка бирү пункты мәйданчыгында урнашкан электр самокатларын прокатка бирү пункты объектын һәм мөлкәтне кабул итү-тапшыру
акты

________________________исеменнән, алга таба «хакимият» дип исемләнүче Башкарма комитетның _____________ районы хакимияте, __________________ исеменнән, алга таба «Махсуслаштырылган оешма» дип исемләнүче___________________ электр самокатларын прокатка бирү пункты объектының хуҗасына (иясенә) прокатка бирү пункты объектында, мәйданчыгында ачыкланган мөлкәтне алга таба «Мөлкәт хуҗасы дип исемләнүче ______________________________ кире кайтардылар, ә мөлкәт хуҗасы түбәндәге мөлкәтне кабул итеп алды:

| № т/б | Мөлкәтнең исеме | Мөлкәтнең торышы һәм комплектлылыгы | Саны, данә |
|---|---|---|---|
| | | | |
| | | | |

Аерым билгеләре_________________________________________________________
_________________________________________________________________________

Әлеге актның аерым билгеләрендә күрсәтелгәннәрдән тыш (әгәр кулланылса), якларның актта күрсәтелгәннәргә претензиясе юк.

| | | |
|---|---|---|
| Башкарма комитетның<br>______________ районы<br>Хакимияте<br>______________________<br>______________________ | Махсуслаштырылган оешма<br>__________________________<br>__________________________<br>__________________________<br>__________________________<br>__________________________ | Прокат пункты объектында, мәйданчыгында ачыкланган прокат пункты объектының, мөлкәтнең хуҗасы (иясе)<br>______________________ |

Башкарма комитет Аппараты
Җитәкчесе урынбасары,
эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы Н.И. Галиева